Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегенең Свияжский бистәседнә гражданнар җыенының
«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегенең Свияжский бистәседнә гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм 2021 елда үзара салым кертү турында»
2020 елның 24 нче ноябрендәге 1нче номерлы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлегенең Свияжский бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш), 1000(бер мең) сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертүгә рөхсәт итәсезме »дигән мәсьәлә буенча 2020 елның 24нче ноябрендә Свияжский бистәсе гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

Свияжский бистәсендә су белән тәэмин итүне оештыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 433 кеше кертелгән, җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 234 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенында катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 224 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 10 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Каратун авыл җирлегенең Свияжский бистәсе территориясендә халык җыенын узган, Халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегенең Свияжский бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар , балачактан инвалидлар; коляскадагы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш),2021 елда 1000(бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга һәм - түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

Свияжский бистәсендә су белән тәэмин итүне оештыру.

3. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегенең Свияжский бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, балачактан инвалидлар; коляскалы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш) 2021 елда 1000(бер мең) сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

Свияжский бистәсендә су белән тәэмин итүне оештыру

4. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

Каратун авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Сабирҗанова